КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 24 август г.Казань № 725

2020 елда «Илкүләм җилкәнле лиганың II этабы» җилкәнле спорт ярышларын һәм «Чайка» пассажир судносын тәкъдир итү чарасын үткәргәндә Татарстан Республикасы территориясендә су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 һәм 25 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 1.3 пункты нигезендә, 2020 елда «Илкүләм җилкәнле лиганың II этабы» җилкәнле спорт ярышларын һәм «Чайка» пассажир судносын тәкъдир итү чарасын үткәргәндә кешеләрнең тормыш куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларындаТатарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ :

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2020 елның 24-30 август көннәрендә көн саен 10.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр Казансу елгасында «Миллениум» күпереннән Кремль дамбасына кадәр («Илкүләм җилкәнле лиганың II этабы» җилкәнле спорт ярышларын һәм «Чайка» пассажир судносын тәкъдир итү чараларын үткәрү зонсы) кече үлчәмле судноларны, шулай ук җилкәнле, ял итү өчен, спорт судноларын, шул исәптән гидроциклларны, байдарка, ишкәкле көймәләрне куллануны тыю;

әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән судноларны куллануны тыю «Илкүләм җилкәнле лиганың II этабы» җилкәнле спорт ярышларын һәм «Чайка» пассажир судносын тәкъдир итү чараларын әзерләү һәм уздыру өчен җәлеп ителгән

судларга кагылмый.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

бу карар белән билгеләнгән тыюны үтәү максатларында Казансу елгасы акваториясендә кизү торуны тәэмин итәргә;

кертелә торган тыю турында халыкка хәбәр итү эшен оештырырга, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша да.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенә әлеге карарда билгеләнгән тыюны үтәү максатларында кизү торуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин